РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423979 РТ Муслюмовский район,с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная, д 31а*
Vbash.Mus@tatar.ru тел.8(8-5556)3-07-20

---

**К А Р А Р № 5**

Вәрәшбаш авылы 5 нче март 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Вәрәшбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 25 нче февралендәге 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә түбәндәгеләрне өстәп, үзгәреш кертергә:

**1.1. 10 пунктның 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән дәвам итәргә:** «һәм мәҗбүри рәвештә салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булмау турында Россия Федераль салым хезмәтеннән белешмә.».

**1.2. 10 пунктны 3 нче абзац белән тулыландырырга:** «мөрәҗәгать итүче 10 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, җирле үзидарә органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләрне мөстәкыйль рәвештә соратып ала».

**1.3. 20 пунктны түбәндәге 4 пунктча белән тулыландырырга:** «4) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З.М.Маннапова**